# Колхоз бөек ватан сугышы елларында.

Колхоз идарәсе язгы чәчүне уңышлы башкару өчен трактор-чыларны башка колхозга качмаслык итеп ашау-эчү ягын кайгырта уңай шартлар тудыра."Тамак ягы" яхшы оештырыл-гач, башка колхозлардан да траклар килә,күп кенә чирәм,чүп үләне баскан җирләр сөрелә чәчү уңышлы тәмамлана.

Шытымнар да яшел хәтфәдәй үсеп китәләр,кызганычка каршы игеннәрне бик көчле боз сугып китә.Игеннәрнең 60% кара җиргә әйләнә. Салам белән ябылган түбәләр калмый,боз тәрәзәләрне ватып бетерә. Бәла өстенә бәла...

Явыз дошман килә ил өстенә,
Ил байлыгын талап җыярга.
Алып килә канлы палачларны
Халкыбызның канын коярга.

Бөек Ватан сугышына безнең авылдан кеше китеп, кеше кире әйләнеп кайтмады. Сугыш елларында бөтен авырлык хатын-кызлар,бала-чага җилкәсенә төшә.Сугыш елларында Татар-стан 131млн.пот бөртекле ашлык тапшырды.

Сугыш рәхимсез ул.Күпме шәһәр-авыллар көлгә әйләнде. Күпме ятимнәр калды.

## Сугыштан соңгы еллар.

Илебез тыныч төзелеш чорына күчә.Партия һәм хөкүмәте-без игенчелекне күтәрү өчен колхозларда звено системаларын кертүне таләп итә.С.Җәләев җитәкчелегендә бөртек җитеш-терү звеносы төзелә.Аларга җир бирелә. Язгы кыр эшләренә керешкәнче үк,звенога бирелгән мәйданнар эшкәртелеп чәче-лә.Колхоз буенча чәчү дә озакка сузылмый. Сугыш вакытында чәчелми калган җирләр эшкәртелә.

1948 елда да алдынгы алымнар нигезендә эшләүче, М.Минга-тин, С.Сәлахов, К.Вәлиуллин, С.Җәләев җитәкчелегендә бөр-текле культуралар игү буенча звенолар төзелә.

Бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 19-ар центнер уңыш алуга ирешәләр. М.Мингатин звеносы ВЛКСМның район,өлкә комитетларыннаң Мактау грамоталары белән бүләкләнде.
Бер баш нәселле айгыр,биш баш бия сатып алып колхозда Ә.Хабибуллин җитәкчелегендә нәселле атлар фермасы оеша.
Сугыш елларында ташландык хәлгә килгән, сугышка кадәр

колхозның даны һәм керем чыганагы булган яшелчә бакчасы аякка бастырыла. Бакчаны Г.Зәкиуллин,М.Мәүҗүтов, Х.Гимаевлар җитәкли. Нәтиҗәдә бөртекле культуралар,яшелчә уңышы җыеп алып,беренчелекне яулый. 1948 елда авылга гамәлдән чыккан ГАЗ-ААмашинасы кайта. Машина М.Вәлиу-ллинга тапшырыла. Ул җитәкче Г.Гайнеев белән берлектә запас частьләр табып машинаны аякка бастыра.Аннары район фондыннан яңа ГАЗ-АА машинасы кайта.Машинада И.Галимов эшли. 1958 елга машиналар саны 8 берәмлеккә җитә.

Безнең колхозга дүрт ДТ-54, бер -У-2 тракторы, дүрт С-4 маркалы үзйөрешле бөртек комбайны бирелә. Бригадиры Мөктәсим Абзалов, ярдәмчесе Габделхак Гиляҗев,тракторчы-лары К.Сафин, З.Ситдыйков, З.Шәмсетдинов, Б.Саттаров, С.Зыяков, Х.Шәфигуллин, З.Мурадыймов, Г.Гатауллин, Ә.Вә-лиуллиннар туган колхозларына кайталар.

Авыл халкы аларга чиксез рәхмәтләрен белдерәләр. ФАП мөдире Ф.Нуруллин хөкүмәтебезнең олы бүләге- Почет билгесе орденына лаек була.

Алардан соң Ф.Сарыймова, Ш. Мортазина, К.Бикмәметова, М.Булатова, Г. Мортазина, К.Галиуллиналар шәфкать туташ-лары булып эшлиләр. 1985-86 елда колхоз рәисе С.Кәлимул-лин, төзүче-техник С.Сарыймов авыл халкына кыска вакыт эчендә профилакторий төзетәләр. Анда электр белән дәвалау, теш врачы өчен кирәкле җиһазлар куела. Биредә Д.Бәдриева, Х.Әхмәтҗанова эшлиләр. Кызганычка каршы 1991 елда профилакторий тулысынча янып бетә.

1938 елда манарасыз калган мәчет, китапханә вазифасын үти. Колхоз идарәсе яңа мәдәният йорты төзүне планга кертә.

Прораб Хатыйп Шакиров җитәкчелегендә проект нигезендә Чирмешән МСОсы аркылы мәдәният йорты төзелә башлый. Төзелеш озакка сузылса да, китапханәсе, махсус кинокамера-сы, бию, спорт залы, 300 урынга исәпләнгән биек, якты тамаша залы булган мәдәният йорты 1972 елның Җиңү бәй-рәме көнне тантаналы шартларда файдалануга тапшырыла. Китапханәдә С.Галимов, Г. Нурутдинова, Р.Вильданова, Р.Бәдриева, Р.Мортазина, мәдәният йорты директоры булып Җ.Шәймарданов, Х.Абзалов, Р.Миннаков, Ф.Закировлар эшлиләр.

Юл газабы, гүр газабы-ди халыкта. Ульяновка авылында Сөлчә аша 1961 елда төзелгән күпердән үтүләре мең газап, ул озакка түзми, җимерелә. Нагорный аша 2 колхоз көче белән кечкенә генә күпер төзелә. әмма таулы юллар булганга

маши-налар иза чигәләр, машиналарны калдырып кайтып китәләр яки кунып калалар. Идарә район җитәкчеләре белән берлектә Әлмәт төзү идарәсебелән элемтәгә кереп капиталь күпер төзү турында килешү төзелә.

Авылны икегә бүлеп агучы Кыязлы һәм сөлчә елгалары аркылы күперләр салына, күперләртирәсенә йөзләгән кубо-метр туфрак ташырга туры килә. 1977 елда Бөек Октябрь революциясенең 60 еллык юбилеена Ульяновка белән Яңа Кади авылы арасында 4 километрда юл күтәрелеп бетә. Аннан соң авылдагы Дзержинский һәм Совет урамнарында юл күтә-реләә.

Халыкка сәүдә хезмәтен яхшырту йөзеннән райпо белән колхоз идарәсе килешү төзи һәм хуҗалык исәбе нигезендә яңа кибет төзелә. Заманча җиһазландырган 720м мәйдандагы кибет файдалануга тапшырыла.

1980 елда авылда 370 хуҗалык һәм 1352 кеше, шуның 599 хезмәткә яраклы дип санала. Кызыл чишмәдә 22 йорт була.

1971-1972 елларда полиэтилен суүткәргеч сузыла һәм тор-балар ярдәмендә Совет, Вахитов, Киров, Чапаев, Гыйрфанов исемендәге урамнарга 26 колонка урнаштырылган.

1986 елда колхоз идарәсе, мәктәп дирекциясе балалар бакчасын аякка бастыруны планлаштыралар. Башлангыч мәктәп бинасын капиталь ремонтлап,электр җылыт-кычлары урнаштырып, заманчалап җиһазландырыла. Балалар бакчасын өл-гертүдә төзүчеләр-С.Сарыймов җитәкчелегендә Т.Гатауллин бригадасының, авыл со-веты председателе Ә.Булатовның мәк-тәп директоры Р. Җамалиевның хезмәтләре аеруча зур булды. Шулай итеп 25 урынга исәпләнелгән балалар бакчасы бүген дә хәрәкәттә.

## Яңарыш еллары.

1950 елларда үзәк газеталарда колхозларны радиолаштыру, электрлаштыру ту-рында куанычлы хәбәрләр басыла. Озак та үтми радиолгычлар сатып алына. Колхоз рәисе Г.Гайнеев 1954 елда авылны радиолаштыруга зур теләк белән керешә 1955 елда баганалык материал табып,район элемтә бүлеге хезмәткәрләре баганаларны утыртып,чыбык сузып,йорт саен репродукторлар урнаштыралар. Авыл халкы 1957 елның 1 январендә җитәкчеләрнең тәбрикләвен радиодан ишетәләр. 1973 елга ка-дәр радист булып

Г.Мөхетдинов, М.Фатхуллиннар эшлиләр. Г.Мөхетдиновны трак-тор бригадасына хисапчы итеп күчергәч, радист вазифасын Х.Фатыйхов, М.Минва-лиев, Ф.Гамировлар башкаралар.1956 елда колхозның "кесәсе сай" булсада электр станциясе алалар,аның өчен таштан бина өлгертәләр.Электр линиясен тиз арада сафка кертәләр. Станциягә моторист итеп З.Ситдыйков билгеләнә. Станция хезмәт күрсәтә башлый.

1949 елда медицина училищесын бетереп кайткан Фатыйх Нуруллин фельшер булып эшли башлый.Яхшы мөгамәләсе, намуслы хезмәте,шәфкатьлелеге белән ул авыл халкының хөрмәтен яулый. Колхозлашу елларында төзелгән медпункт бинасына ремонт ясала. Кызыл Чишмәдә бала тудыру йорты төзелә. Бөек Ватан сугышында катнашкан Әкълимә Билалова акушерка булып  эшли.